**Республика Татарстан**
**Глава Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

07.06.2023г.

№ 2

Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны билгеләү һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының "Югары Чыршылы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

ФАП территориясе;
мәктәп территориясе;
балалар бакчасы территориясе;
парклар, скверлар территориясе;
балалар уен мәйданчыклары территориясе.

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Камалетдинов Илсур Наил улын хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы
авыл җирлеге башлыгы

И.Н.Камалетдинов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ · РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ОГРН 1031604001000
Совет Верхне-Чершилинского сельского поселения
Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы
ИНН 1636001964